Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

12 ноябрь 2020 ел №3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль
районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 24 ноябрендә сәгат 09.00 Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләп үтәргә. Халык җыенын авыл клубы бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Үрәсбаш авылы, Пионерская урамы, 21 йорт.
2. 2020 елның 24 ноябрендә сәгат 15.00 Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләп үтәргә. Халык җыенын АО «Кукморагрохимсервис» ярдәмче хуҗалыкның правление бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Үрәсбаш авылы, Октябрьская урамы, 40 йорт.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: "Сез яшәү урыны буенча Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылы территориясендә теркәлгән көндезге уку бүлегендә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар һәм 80 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала һәр балигъ булган яшәүчедән 2021 елда 900 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны:

- Үрәсбаш авылы Пионерская урамы буенча юлларына асфальт салу; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек өчен шартлар булдыру кебек эшләр башкаруга юнәлтү белән ризамы?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билгеләр (урамнар буенча) буенча бүлергә.
5. Түбән Үрәс авыл җирлегенең башкарма комитеты гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

6. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында җирлекнең «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә игълан итәргә.
7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс Авыл
җирлеге башлыгы: Р.Х.Шамеев

ОГРН 1061675011045
ИНН 1623008521